| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

10.03.2020 — № 123

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы
Башкарма комитетының 2016 елның 29 августындагы
779 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Хөкүмәтнең «Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында якынча нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 10 февралендәге 120 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 29.08.2016 ел, № 779 карары белән расланган Балаларны вакытлыча карап торучы гаиләләрдән дәүләт оешмаларына кайтару очракларын анализлау буенча муниципаль эксперт комиссиясе турындагы нигезләмәгә (2 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Нигезләмәнең 4 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 Комиссия составы.

4.1 Комиссия составына комиссия рәисе, комиссия рәисе урынбасары (урынбасарлары), комиссиянең җаваплы секретаре һәм комиссия әгъзалары керә.

4.2. Комиссия әгъзалары булып профилактика системасы органнары һәм учреждениеләре җитәкчеләре (аларның урынбасарлары) тора, шулай ук башка дәүләт (муниципаль) органнары һәм учреждениеләре вәкилләре, иҗтимагый берләшмәләр, дини конфессияләр вәкилләре, балигъ булмаганнар белән эшләү тәҗрибәсе булган гражданнар, тиешле вәкиллекле органнар депутатлары, башка кызыксынучы затлар булырга мөмкин.

4.3 Комиссия рәисе, рәис урынбасары, җаваплы секретаре һәм әгъзасы булып 21 яшькә җиткән Россия Федерациясе гражданы булырга мөмкин.»

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче — Л.Н. Маняпов